Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 20 (33)

21 июнь 2012 ел

## • Ике авыз сүз

**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ һәм УЛЬЯН ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ ТАРАФЫННАН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮ ТУРЫНДА КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЕЛДЫ.** Документны КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм Ульян өлкәсе губернаторы Сергей Морозов имзалды. Ике як арасында мәгарифне үстерү һәм икътисад үсешендә инновацион технологияләрне кулланып, сыйфатлы белем бирү турында килешү төзелде. Килешүдә КФУ һәм Ульян өлкәсенең хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә уку-укыту өлкәсендә яңа юллар ачылуы, бизнес, икътисад, фән һәм башка әһәмиятле өлкәләрдә киңрәк планда эшләү мөмкинлеге булачагы күрсәтелгән. Алга таба мондый төрдәге килешү Чувашия һәм Удмуртия республикалары белән дә төзелер дип көтелә.

• • • •

18 июнь көнне дөньяның алдынгы бизнес һәм хөкүмәт эшләрен алга җибәрү өлкәсендә эшләүче экспертларның берсе **ДОКТОР ИЦХАК КАЛЬДЕРОН АДИЗЕС КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНДА ЛЕКЦИЯ УКЫДЫ**. Аны тыңларга университетның профессорлары, галимнәр, укытучылар һәм студентлар җыелган иде.

Доктор Ицхак Кальдерон Адизес – идарә итү теориясе буенча күпләгән тикшеренүләр һәм китаплар авторы. Үзенең чыгышында да ул нәкъ шушы өлкәгә басым ясады. «Идарә итүнең нәтиҗәсе кешеләрнең бер-берсенә хөрмәте һәм бер-берсенә ышанычы булганда гына уңышлы», – диде ул.

Университетыбыз кунагы хаталанудан курыкмаска, үзгәрешләргә һәрвакыт әзер булырга чакырды. Үзгәрешләр ул – тормыш, әгәр дә алар бетсә, тормыш та бетә дигән сүз. Үзенчәлекле, фәлсәфи лекциядән тыңлаучылар зур дулкынлану белән таралышты.

• • • •

**30 ИЮНЬ КӨННЕ** Казан университеты Кайгыртучанлык советының утырышлар залында **«ДИН ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ДӘҮЛӘТНЕҢ КОНСТИТУЦИОН ХОКУКЫ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН «ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ» УТЫРЫШЫ УЗАЧАК**. Әлеге чара Коръән елы булу уңаеннан оештырыла (2012 елны РТ Мөселманнар Диния нәзарәте Коръән елы буларак билгеләде). Чараны оештыручылар – КФУ ның юридик факультеты һәм ТР Мөселманнар Диния нәзарәте. «Түгәрәк өстәл»нең темасы итеп Россиядә җәмгыять, дин һәм дәүләтнең үзара тәэсир итешүе сайланды. Очрашу ТР ның Президент Аппараты, ТР Дәүләт Советы, ТР Конституцион суды һәм башка әлеге өлкәгә кагылышлары булган оешмалар катнашында узачак. «Түгәрәк өстәл» утырышы иртәнге тугызда башлана.

• • • •

**ПЕДАГОГИКА ҺӘМ ПСИХОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ УКЫТУЧЫЛАРЫ**, Латвиядә укытучыларның квалификациясен арттыру системасы белән якыннан танышу өчен, **РИГА УНИВЕРСИТЕТЫНА КИТТЕ**. Алар шулай ук «Көчеш психологиясе: мәктәп укучысыннан профессионалга кадәр» дип аталган халыкара конференциядә дә катнашачак. Визитның төп максаты булып Латвиянең югары уку йортлары белән килешүләр төзү тора.

Педагогика һәм психология институты вәкилләре Калининград шәһәрендә бишенче тапкыр уза торган когнитив фәннәр буенча халыкара конференциядә катнаша. Биредә танып белү һәм аның эволюциясе, фикерләү, аралашу чарасы буларак тел белгечләре, психология, лингвистика, нейрофизиология, фәлсәфә, педагогика буенча белгечләр тәҗрибә уртаклашачак. Россия вузларыннан тыш, АКШ, Калифорния, Финляндия, Австралия университетларыннан да белгечләр катнаша.

• • • •

Бер ай элек **«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫНДА** тантаналы рәвештә **«КАЗАН – 2013» ВОЛОНТЁРЛАР ҮЗӘГЕ АЧЫЛГАН ИДЕ**. Волонтёрлар белән эшләү үзәге мәгълүматларына караганда, бүген аеруча уңышлы позицияләр – спорт ярышларын оештыручылар, медиа, аккредитация юнәлешләре һәм атташелар.

Волонтёрлар командасында яшьләр һәм студентлар белән беррәттән, урта яшьтәге кешеләр дә бар. Гомумән алганда, волонтёрлар үзәге, сессия һәм каникул вакыты булуга карамастан, һәр көн саен 40-50 кеше белән әңгәмәләр үткәрә. Тиздән бу сан бер көндә 100 гә җитәр дип көтелә. Исегезгә төшерәбез: Универсиадага барлыгы 20 мең волонтёрны җәлеп итәргә телиләр. Әгәр волонтёр булырга теләсәгез, онлайн-гаризаны түбәндәге адреста www.makeUreal.kazan2013.com тутыра аласыз.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



■ *Россиядәге Фулбрайт программасының директоры Эдвард Рослоф (уңда).* Диана Поварова фотосы

# «Ямь-яшел» технологияләр

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

**Фулбрайт программасы Россиядә инде икенче тапкыр төгәл фәннәр һәм технологияләр буенча Җәйге мәктәп оештыра. Яңа мәктәпнең темасы – «Яшел технологияләр».**

Җәйге мәктәп кичә ачылды һәм ул 20 июньнән 30 ына кадәр Казан федераль университеты базасында Казан шәһәрендә эшлиячәк. Мәктәп программасында семинар-лекцияләр, практик дәресләр, лаборатор-практикумнар, кырга чыгулар, «яшел» технологияләр буенча махсус белгечләр һәм АКШ тан килгән кунаклар белән фикер алышу-бәхәсләр булыр дип көтелә. Шул ук вакытта Җәйге мәктәптә катнашучылар «яшел» технологияләрне төрле өлкәләрдә куллануның үрнәкләре белән дә танышачак. Ахырдан әзләнүчеләргә Фулбрайт программасы буенча Җәйге мәктәптә курслар үтте дигән сертификатлар тапшырачаклар.

Җәйге мәктәпкә Россиянең төрле төбәкләреннән «яшел» технологияләр белән шөгыльләнүче аспирантлар һәм яшь белгечләр чакырыла. Аларның яше 35 тән узмаган булырга тиеш. «Җәйге мәктәп – 2012» гә барлыгы 20-25 яшь галимне сайлап алырлар дип көтелә.

«Яшел» технологияләр табигатьне саклау буенча дөнья күләмендә инде күп еллардан бирле эшләп килә. Бу өлкәдә абруйлы галимнәр зур көч куя. КФУ ның экологгалимнәре дә яшәешебезне табигатькә зыянсыз итү юнәлешендә күп эшли.

Программада «Туфрак һәм калдыкларны биотестлаштыру методлары», «Әйләнәтирәнең пычрануын бәяләүдә биосенсорлар», «Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә калдыкларны эшкәртү: законнар; икътисади механизмнар», «Әйләнәтирәне чистарту технологияләрендә үсемлек-фитомелиорантларның роле», «Үсемлекләрне саклауның биологик чаралары» темаларына лекцияләр, «Биокуркынычсызлыкның заманча проблемалары», «Органик калдыкларны эшкәртү методларын чагыштырма анализлау», «Үсемлекләрнең фотосинтетик һәм сулау активлыгын бәяләү», «Халыкның һәм белгечләрнең «яшел» технологияләрне куллануының әһәмиятенә төшенү: уңай иҗтимагый фикер формалаштыру проблемалары» кебек семинарлар, «Экологик кыйммәтләр һәм үз-үзеңне тоту: кешеләр «яшел» технологияләрне кулланырга әзерме?» дип аталган «түгәрәк өстәл» каралган. Шулай ук Казан шәһәре буйлап, Зөягә, Биомасса үзәгенә, Раифага сәяхәтләр оештырылачак.

## • Фән дөньясында

# Чит телгә - заманча

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

**Кичә, ягъни 20 июнь көнне университетта «Хәзерге заманда чит телләр: телләрне һөнәри һәм махсус өйрәнүнең актуаль проблемалары» дип аталган V Халыкара фәнни-гамәли конференция ачылды. Ул үзенең эшен бүген дә дәвам итә.**

Кичә дә, бүген дә конференция кысаларында мастер-класслар каралган иде. Алар узганнан соң, галимнәр «Лингвистика», «Югары уку йортларында чит телләргә өйрәтүнең психологик-педагогик аспектлары», «Әдәбият белеме. Лингвострановедение. Мәдәниятара багланышлар», «Югары уку йортларында чит телләргә өйрәтүнең методик аспектлары» кебек дүрт эре секциягә бүленеп эшләде. Чараның төп оештыручылары – КФУ ның Телләр институты.



Алия Галимуллина фотосы


• Бәйге

# «Сабантуй гүзәлләре» арасында КФУ Гүзәле дә бар…

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

САБАНТУЙ – САГЫНЫП ҺӘМ ЕЛНЫҢ УҢЫШЛЫ БУЛУЫН ТЕЛӘП, КӨТЕП АЛГАН ИҢ ХӨРМӘТЛЕ БӘЙРӘМ. УЛ КҮҢЕЛ АЧУ, БӘЙРӘМ ИТҮ ГЕНӘ ТҮГЕЛ.





Гыйбадәт, сәнгать һәм уенның чыганагы бер: шатлык яисә кайгы изһар итү. Уен дигәне спорт, музыка һәм биюне дә үз эченә ала. Ат чабышы, көрәш, Сабантуй бүләкләре – ярышлар өчен күрекле тукымалар хәстәрләү, гармун моңнары – боларның барысы да тереклекнең матур яшәешен күрсәтә торган сәнгать системасы, миллилек билгеләре.

Дөнья бер рәвештә тормый, әлбәттә. Заман таләпләренә туры китереп, Сабантуйның төп сыйфатын бозмый торган яңалыклар да өстәлеп тора. Яр Чаллы шәһәрендә исә шундый матур бер традиция бар. Бәйрәм хуҗабикәсен – «Сабан туе гүзәлен» сайлаудан гыйбарәт. Ул быел инде XVII тапкыр үткәрелә. Бәйгедә 18-23 яшьлек кызлар катнаша. Конкурсантлар арасында КФУ ның Яр Чаллы филиалы филология һәм журналистика факультеты студенты Гүзәл Сәләхетдинова да бар иде. Конкурс ахырында Гүзәл «Иң заманча» дигән номинациядә җиңү яулады.

«Беренче чыгышымда микрофон янына сүз әйтергә килгәч, нык дулкынланган идем. Аннан соң барысы да үзеннән-үзе, бернинди каушаусыз гына, җиңел барды. Бу тантанадан чиксез эмоцияләр белән кайттым», – диде ул хис-кичерешләре белән уртаклашып.

Чыннан да, «Сабантуй гүзәле»н сайлау көтеп алынган бәйрәмебезгә тагын бер ямь, үзенчәлек бирә кебек. Ә безнең вуз студентлары да катнашуы һәм җиңүе горурлык хисләре генә өсти!

• Галимнәребез

# «Вуз укытучысының яше 23 тән дә арта алмый…»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

ПРОФЕССОР ӘНВӘР НУРИӘХМӘТ УЛЫ ХУҖИӘХМӘТОВНЫ СТУДЕНТЛАРГА КАРАТА ИГЪТИБАРЛЫ, ҮЗ ЭШЕНӘ БИК ҖАВАПЛЫ КАРАУЧЫ, ЧЫП-ЧЫН ПЕДАГОГ БУЛАРАК БЕЛӘ ИДЕМ ИНДЕ. УНИВЕРСИТЕТ КОРИДОРЫННАН ҮТЕП БАРГАНДА ДА АНЫҢ СТУДЕНТЛАРГА КАРАП: «ХӘЕРЛЕ КӨН, ХӨРМӘТЛЕ КОЛЛЕГАЛАР!» – ДИГӘН КӨР ТАВЫШЫН ҺИЧ КЕНӘ ДӘ ИШЕТМИЧӘ БУЛМЫЙ. ОЗАКЛАМЫЙ ӘНВӘР НУРИӘХМӘТ УЛЫНЫҢ 60 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЕ. БУ УҢАЙДАН БЕЗ АНЫҢ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ КОРЫП АЛДЫК.

**– Әнвәр Нуриәхмәтович, сүзебезне сезнең туган-үскән яклардан ук башлыйк әле...**

– Мин үзем Болгар төбәгендә туып-үстем. Балачагым Йолдыз дигән авылда үтте. Әтием Нуриәхмәт һәм әнием Зөлхәбирә ун бала тудырып үстергәннәр. Аллаһы Тәгалә парлаштырып, безнең гаиләгә 5 малай, 5 кыз биргән. Мин 8 нче бала булып дөньяга килгәнмен, малайлар арасында төпчеге. Һәм төпчек малай булуым минем өстәге җаваплылыкны тагын да арттыра төште. Бу, әлбәттә, династия, әтиәнине карау һәм башка йөкләмәләрне үз эченә алу белән бәйледер...

**– Ирешкән дәрәҗәләрегездән чыгып карасак, мәктәптә ничегрәк укуыгызны күзаллау авыр түгел. Ә шулай да, Әнвәр абый, мәктәптә Сез ниндирәк укучы идегез?**

– Мактанып әйтү кебек кабул ителмәсен, мәктәптә мин «круглый» отличник дигән исем йөртә идем. «4» ле, «3» ле һәм «2» ле билгеләрен, гомумән, белмәдем. Һәр класста элек бит гел «5» легә укучы балаларга грамоталар бирелә иде, ул грамоталарымны истәлек итеп хәзерге көнгә кадәр саклыйм. Шул ук вакытта бик тә иҗади малай идем. Мәкаләләр язарга ярата идем. Шулай итеп, «Ялкын», «Пионерская правда», «Яшь ленинчы» кебек балалар матбугатының актив хәбәрчесенә әйләндем.

**– Шул елларның кайсы мизгелләре әле дә хәтер сандыгыгызда саклана?**

– VII класста укыганда, «бик яхшы» билгеләренә укыган өчен «Пионерская правда» газетасы Бөтенроссия «Бөркеткәй» пионер-лагерена җибәрде. Ә VIII сыйныфта исә ВЛКСМ ның өлкә комитеты һәм хәзерге «Сабантуй» газетасы редакциясе мине «Артек»ка юллама белән бүләкләде. Үземдәге үзгәрешләрнең дә мин нәкъ менә шунда башланганын сиздем. Дөньяның бөтен төбәгеннән килгән яшүсмерләр белән аралашу, яңа мохиткә эләгү тормышка мөнәсәбәтемне бөтенләй башка якка таба үзгәртте. Балачакның әлеге мизгелләрен әле дә бер сагыну хисләре белән искә алам.

**– Мәктәптә кайсы фәннәрне бирелеп укыдыгыз?**

– Миңа төгәл фәннәр ошый иде: математика, физика. Бу өлкәгә караган мәсьәләләрне бүген дә бернинди авырлыксыз чишеп бирә алам. Укытучылар да, туганнар да мине я математик, я физик итеп күзалладылар. Әтиәниемнең исә авыл хуҗалыгы институтында укытасылары килде, чөнки үземнән зуррак 4 абыем барысы да хәрбиләр, туган нигездә калырга тиешле кеше бердәнбер малай мин идем. Әмма язмышыма шулай язылган булгандыр инде: КДУ га журналистика юнәлеше буенча укырга кердем. 4 ел буе параллель рәвештә төрле газеталарда эшләп, уңышлы гына укуымны тәмамлап, Казанда журналист булып эшкә калырга җыенып йөргән көннәрдә әнием бик каты авырып китте. Миңа кичекмәстән авылга кайтырга кирәк иде... Шул вакыттан башлап тормышымның бөтенләй өр-яңа бите ачылды.

**– Димәк, педагогик юнәлештәге эшчәнлегегезгә нигез авыл җирендә салынды?**

– Әйе, авылга кайткан 22 яшьлек югары белемле егет нишләп ятарга тиеш инде?! Мине аз гына эшләп торырга дип мәктәпкә чакырдылар. Һәм мәктәп дөньясы белән шулкадәр мавыгып китеп, бөтен көчкә эшли башладым. Алга таба һаман саен югарырак дәрәҗәдәге эшләр тәкъдим ителде: завуч, директор, РОНО хезмәткәре, Казанда министрлыкта, аннары университетта... Аллага шөкер, һәрбер этап үз вакыты һәм хәерле сәгате белән барды.

**– Гаиләгез белән дә таныштырып үтсәгез иде.**



– Җәмәгатем белән ике бала үстерәбез. Олы улым Динар – фәннәр кандидаты, Социаль һәм гуманитар белем бирү институтында укыта. Кызым Зөлхәбирәгә (әниемнең исемен куштым) 8 яшь, 33 нче эксперименталь мәктәптә бик теләп, яхшы гына укый. Аның укуга карата булган тырышлыкларын күреп куанып-сөенеп йөрим.

**– Студентларыгызга карата аерым таләпләрегез бармы?**

– Мин үзем тәртип ярата торган кеше. Һәм үзем укыткан студентлардан да шуны таләп итәм. Беренчедән, мин җәмәгать урыннарында, бигрәк тә югары уку йортында тиешсез киемнән йөрүче студентларны аңламыйм. Шунлыктан беренче лекцияләремдә үк аларны кисәтеп, тиешле формадан йөрергә кирәклекне төшендереп куям. Әгәр тәрбия-укыту эшендә уңышка ирешәм дисәң, анда буйсыну дигән әйбер булырга тиеш. Диктатура дигән төшенчәгә игътибарлы булырга кирәк. Икенчедән, укучыларның яшьтән культуралы булып үсүләренә зур басым ясыйм. Мисал өчен, театр-концертларга йөргән студент, олыгайгач та бу эстетик юнәлештәге белемнәрен искә төшерә, элементар гына әйбер: кайда күлмәк-галстуктан барырга кирәк, кайда нинди форма булырга тиешлекне дә белеп үсә!

**– Тиздән Сезнең 60 яшьлек юбилеегыз җитә, ләкин йөзегезгә карасаң, һич кенә дә алтынчы дистәне түгәрәклисез дип әйтеп булмый... Моның сере нидә икән?**

– Укыган вакытта мин спорт белән ныклап шөгыльләнә идем. Ул гадәтем бүгенге көнгәчә сакланды: әле дә йөгерәм. Һәм, миңа калса, укытучылар алар беркайчан да картаймыйлар, укытучылар алар үзләре укыткан балалар яшендә булырга тиеш. Башлангыч сыйныфта укытучы кеше үзен 8-9 яшьлек итеп хис итә икән, зуррак сыйныфларда – 12-15 яшьтә һәм инде югары уку йортларында ул үзен 20-23 яшьтә кебек хис итсә – бик нормаль һәм дөрес күренеш. Шуңа күрә мин үземә 23 яшьтән дә артыгын бирә алмыйм әле.

**– Әңгәмәбез ахырында студентларыгызга нинди киңәшләрегезне җиткерер идегез?**

– Яшьтән үк компьютердагы сыман киләчәкнең программасын башларына төзеп куйсыннар иде. Шуңа омтылып, этаплап максатларына туры атлап барсалар, бу тормышта һәрнәрсәгә ирешә алачаклар!

**– Җылы әңгәмәгегез өчен рәхмәт, юбилеегыз белән котлыйбыз Сезне!**

● Абитуриент колагына

# Педагог булыйм дисәң...

Балаларга белем һәм тәрбия бирүдән дә изгерәк тагын нинди һөнәр ияләре бар икән? Укытучы ул кеше язмышына нигез салучыларның берсе, ата-анадан соң бала тормышында иң мөһим урынны алып тора.

### *Ихтыяҗ*

Балалар бакчасында, мәктәп, урта һәм югары уку йортларында белем биргән мөгаллимнәребез безне гомернең азагына кадәр озата бара. Без авыр вакытларда аларның киңәшләренә колак салабыз, шатлык-уңышларыбызга бергәләп сөенәбез. Шул һөнәргә кечкенәдән үк гашыйк булганнар үзен киләчәк буынга гыйлем-тәрбия бирүгә багышлый. Әлеге юнәлеш буенча тәпле һәм югары белем алырга теләүчеләрне Казан федераль университетында көтәләр.

### *Кемнәр әзерләнә*

Уку йортыбызның Педагогика һәм психология институты 2011 елның сентябрь аенда оеша. Аның структурасына түбәндәгеләр керә:

– психология бүлеге;

– педагогика бүлеге;

– Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге.

Биредә педагогика һәм психология юнәлеше буенча бик күп белгечләр әзерләнә.

Психология, социаль педагогика, логопедия, махсус психология белгечлекләренә укырга керү өчен, биология, математика һәм рус теле буенча бердәм дәүләт имтиханы тапшыру кирәк.

Башлангыч белем бирү белгечлегенә кергәндә, төп игътибар математика һәм рус теленнән тыш, җәмгыять белеме буенча БДИ нәтиҗәләренә бирелә.

### *Студентлар*

Институт студентлары бик актив яши. Спорт ярышларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә уңышлары мактанырлык, мәдәни-күңел ачу чараларында катнашалар. Тарихи мирасыбызны саклау, институт күләмендә төрле семинар, «түгәрәк өстәл»ләр, студентлар өчен ял сәгатьләре оештыру буенча да актив эш алып баралар. Студентлар үзләрен төрле яклап ача һәм талантларын күрсәтә ала, чөнки биредә бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган.

Педагогика һәм психология институтындагы белгечлекләр турында тулырак мәгълүматны түбәндәге сылтама буенча кереп карый аласыз: http://new.kpfu.ru/main_page?p_sub=5352.

● Яңа китап

# Кечкенәдән килгән тәҗрибә

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче



Алдагы санда журналистика һәм социология факультеты доценты Җәүдәт Акчуринның «Заманча журналистика нигезләре» дип исемләнгән кулланмасы басылуы турында хәбәр иткән идек. Галимнең фотожурналистика өлкәсенә килүе дә бик кызыклы.





«Өйдә «Фет» маркалы фотоаппарат бар иде. Шуның белән төшереп карарга булдым. Мин VIII-IX сыйныфларда укыган вакыт бу. Башта дусларымны төшерүдән башладым, уңышлы гына сурәтләр чыкты. Алга таба фотосурәткә төшерергә өйрәтә торган югары уку йортын эзләргә керештем», – дип искә ала Җәүдәт әфәнде. Бу вакытта ул Казанда һәм Куйбышевның кинохроник студиясендә оператор булып



эшли. Аңа, киносюжетлар әзерләү өчен, бөтен республика буенча йөрергә туры килә. Шуңа күрә ул югары белемне полиграфия институтында читтән торып алырга мәҗбүр була.

Студент вакытта ук фотожурналист карьерасына нигез сала. Ун ел дәвамында республиканың алдынгы газета-журналларында эшли һәм гамәли фотожурналистика өлкәсендә тәҗрибә туплый. Журналистика һәм социология факультетына укытучы итеп чакырылгач, студентларга үз белгәннәрен өйрәтә башлый. Укытуда теория белән гамәлне берләштереп, әлеге өлкәдә яңа ачышлар ясый. Шушы педагогик эшчәнлек барышында тупланган тәҗрибәләргә таянып, Мәскәүдә документаль фотография буенча диссертация яклый. Фотожурналистика дөньясына яңа сулыш алып килә. Нәтиҗәдә, бай мәгълүматлы, студентларга фотожурналист белгечлеген алырга ярдәм булган «Заманча журналистика нигезләре» басмасы дөнья күрә.

Басма фотосурәткә төшерүнең имиджын күтәрү максатын тормышка ашыра. Мондый характердагы укыту кулланмалары моңарчы басылмаган. Аның уникальлеге дә шунда. Басма әлеге юнәлеш буенча белем алучылар өчен генә түгел, ә фотосурәткә төшерү белән шөгыльләнә башлаучылар өчен дә зур ярдәм булачак.

***P.S.** Китапны журналистика һәм социология факультетының икенче катында урнашкан китапханәсендә алырга мөмкин. Белешмәләр өчен телефон: 8 917 291 11 00.*

● Сәяхәттән кайткач

# КФУ тагын 6 мәктәп белән дуслашты

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

15 июнь көнне Педагогика һәм психология институты педагогика кафедрасының бер төркем галим-мөгаллимнәре, аспирант һәм студентлар белән Спас районында эшлекле очрашуларда һәм тарихи урыннарда сәяхәттә булып кайттык.

Иртәдән үк кояш якты нурларын бүләк итте. Әйтерсең, юлларыгыз якты, кылган гамәлләрегез нәтиҗәле булсын, дия. Кояштан да нурлырак йөз белән остазыбыз Әнвәр абый Хуҗиәхмәтов каршы алды. Чараны оештыручы, барыбызны бергә җыйнап, шундый күңелле һәм файдалы мизгелләр бүләк итүче дә ул бит.

Юлчының юлда булуы хәерле дигәндәй, без дә юлга кузгалдык. Табигатьнең матурлыгына исең китәрлек. Шәһәр шау-шуыннан туйган кешегә авыл җиреннән дә рәхәтрәк җир бар микән соң?!

### *Тарих һәм киләчәк...*

Спас районы Татарстанның көньяк-көнчыгышында, табигатьнең бик матур бер кочагында урнашкан. Районның үзәге Болгар шәһәре тарихи мирасыбыз, сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәгебез булып тора. X гасырда нигез салынган Болгар шәһәре халыкара сәүдә үзәгенә әверелә. Авыл хуҗалыгы да алга китә. Район халкы эшчән, ярдәмчел, киң күңелле. Халыкның 90% руслар тәшкил итә. «Безнең коллектив та катнаш. Дустату яшибез, эшлибез. Горурланырлык уңышларыбыз да бик күп, үткән белән бүгенге тарихыбызны киләчәк буынга тапшыру өчен бар көчне куябыз», – диде очрашу барышында администрация башлыгы Камил Әсгать улы Нугаев. Шулай ук бөтен район халкы исеменнән якташлары Әнвәр Хуҗиәхмәтовка зур рәхмәт сүзләре җиткерде һәм аның белән чиксез горурлануын әйтте.

Көн тәртибе буенча алга таба мәктәпләрнең эшчәнлеге белән якыннан таныштык. Болгар шәһәренең икенче номерлы мәктәбендә төпле белем, ныклы тәрбия алу, буш вакытны кызыклы һәм файдалы итеп үткәрү өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Заманча җиһазландырылган кабинетлар, кызларга аерым хезмәт дәресе өчен эшләнгән бүлмәләр, егетләргә эш кораллары белән тәэмин ителгән остаханәләр укучыларның уңышлары да горурланырлык булуы турында сөйли.

Казан университеты Спас районы мәктәпләре белән күп еллар дәвамында хезмәттәшлек итә. Бу көнне Казан федераль университеты 6 мәктәп белән килешү төзеде. Шулай ук Әнвәр Хуҗиәхмәтов мәктәп директорларына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәт хатларын тапшырды. Алга таба мәктәпләрне дәреслекләр, укыту ярдәмлекләре, программалар белән тәэмин итү безнең төп максат булачак. Мәктәп укытучылары бу очракта да остазыбыз Әнвәр абыйга рәхмәтле. Ул ничә еллар дәвамында укучыларның Казанга экскурсиягә килүен, башкалабыз театрларына тамаша кылуын оештырган. Алга таба мондый мәдәни-



■ КФУ профессоры Ә.Хуҗиәхмәтов Болгар интернат-мәктәбе директоры В.А.Четановка Рәхмәт хаты тапшыра

күңел ачу чаралары тагын да күбрәк булыр дип ышана алар.

### *Ил куәте – икмәктә*

Спас районына булган сәяхәтебезнең иң күңелле мизгелләре алда булган икән әле. Күптән түгел генә ачылган Игенчеләр авылы, ягъни Икмәк музее белән танышу мөмкинлеге дә булды безнең. Якты йөз белән каршы алып, бөтен музей территориясе, аның эшчәнлеге белән таныштырдылар. Биредә икмәк бөртегенең ничек үскәненнән алып, өстәлгә ничек килгәненә кадәр күрергә мөмкин. Җил тегерменендә тартылган оннан ипине утын мичендә пешерәләр. Аны авыз итеп карарга, сатып алырга мөмкин. Бөтен кирәк-яраклары белән тегерменче йорты да бар. Ындыр табагында ашлыкны киптерә, суга һәм саклый торган урыннар да каралган. Хәтта кечкенә-кечкенә генә басуларда төрле бөртеклеләрнең ничек үсүен, игелүен дә күрергә мөмкин. Авыл тормышын сиртмәле кое, күл һәм инештән башка күз алдына китереп булмый. Алар да бар. «Кечкенә авыл»ның мал-туарлары да җитәрлек. Сыер, бозау, атлар, каз-үрдәкләр, тавыклар музейны тагын да тулыландырып җибәрә. Килгән туристлар үз куллары белән нәрсә дә булса эшләп карасын өчен, тимерчелек, чүлмәкчелек урыннары да булдырылган. Истәлеккә матур сувенирлар сатып алырга мөмкин.

### *Кечкенә хаҗ*

Болгар тыюлыгы – федераль дәрәҗәдә Татарстан Республикасы өчен тарихи һәм мәдәни мирас буларак бик әһәмиятле объект. ТР Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» фонды җитәкчесе Минтимер Шәймиев, бай тарихи мирасыбызны саклап калу, аны читтә яшәүче милләттәшләребез, дин кардәшләребезгә якынайту өчен, бик изге эшләр башкара. Экскурсоводыбыз да әлеге мәсьәләгә аерым басым ясады: «Без Ирек статуясын да, Эйфель манарасын да, Төркия, Италияләрне дә яхшы беләбез. Үзебездәге кыйммәтләрне күрмибез, аларның тарихын өйрәнмибез, сакламыйбыз. Яшь буын рухи кыйммәтләрнең нәрсә икәнен белеп үссен иде», – диде. Дөрестән дә, Төркияләрең, диңгез буйларың бер читтә торсын. Тыюлык хезмәткәрләре әйткәнчә, монда күңел тынычлыгы алырга мөмкин.

Болгар нигезе хәрабәләренә бару кечкенә хаҗ кылу белән бер, диләр. Без дә бу көнне чал тарихка баш ию урыны булган Болгар җирләре белән танышып, бабаларыбыз рухына дога кылып кайттык. Иртәдән үк безнең эш-гамәлләребезне күзәтеп торган кояш, көн кичкә авышканда да куйган максатларыбызның тормышка ашуын, кәефләребезнең күтәренке булуын күреп елмайды.



■ Ак мәчет. Болгар.



■ Икмәк музее. Болгар.

Илһам канатында

**Зөһрә Рифхат кызы ВИЛДАНОВА**

Быел Кукмара районы Фасил Әхмәтов исемендәге Кәркәүч урта мәктәбен тәмамлый. Кечкенәдән үк әдәбият белән кызыксына. Шигырьләр язарга, рәсем ясарга ярата. Әсәрләре вакытлы матбугат битләрендә дә басылып килә. Буш вакытларында әдәби китаплар укырга ярата, ислам дине нигезләрен өйрәнә, чигәргә ярата. «Илһамлы каләм» конкурсының даими катнашучысы булган Зөһрә быел проза юнәлешендә I урын алды. Сезгә аның бер хикәясен тәкъдим итәбез.

# Күңелдәге кояш



Көне дә бүген!.. Бигрәк матур!.. Алтын кояш балкый!.. Яз кояшы, апрель кояшы шундый була бит ул. Тылсымлы нуры күзләрне чагылдыра, күңелләргә үтеп керә, бар авылны нурландыра. Менә шундый көннәрдә үзеңне икенче төрле хис итәсең, ләкин язның салкын көннәре дә булыр әле...

Нәкъ менә шундый кояшлы көннәрнең берсендә Сиринә, гадәттәгечә, мәктәпкә таба атлый. Сәер кыз диләр аны. Сиринә сәгатьләр буе урманда, болында, су буенда йөри ала, сөйләшергә дә алай ук яратмый үзе. Төс-бите дә искитәрлек түгел аның: ябык гәүдә, кыска буй, җирән, әмма бераз коңгыртрак чәчләр, зур олы, чирәм төсле ямь-яшел күзләр. Шуңа да өнәп бетермиләр аны. Сәгатьләр буе интернетта утырганнарны аңлыйлар, ә табигатьтә йөрүчеләрне аңламыйлар шул иптәшләре. Иптәш дип әйтеп булмый инде аларны, дуслары юк диярлек Сиринәнең. Тыштан гына шулай гамьсез, сәер булып күренсә дә, аның да үз шөгыле, хыялы, уйлары бар. Табигатьне яхшырак аңлар өчен, озак йөри ул. Дуслары да бөтенләй юк димим әле, бар, Алинә аның исеме, ләкин Сиринә белән алар бөтенләй бер-берсенә туры килмиләр, төгәлрәк әйтсәң, хәтта бөтенләй капма-каршы характер аларда. Алинә купшы киенә, үткен, тере, усал да әле, сыйныфның төп лидеры. Һәрнәрсәдән үзенә файда табучы бу кыз, Сиринә әйбәт укыгач, аның белән дус булуны кирәк тапты. Сиринә, әлбәттә, боларны белми иде. Ул дустын үзенчә якын күрә, аңа ясаган рәсемнәрен дә бик еш бүләк итә.

Уйлана-уйлана юлдан барганда, сыйныфташы Гаяз белән маңгайга-маңгай бәрелешә язды Сиринә.

– Гаяз, сәлам! Әллә мине күрмисең дә инде?

– Гафу, уйга биреледем, яңа «эшем» бар.

Гаязның кушаматы – Шымчы. Киләчәктә детектив булырга хыяллана ул. Шуңа күрә дә сыйныфта кем кайдан күчерә, кем кемгә нинди шуклык әзерли – барысын да белеп тора. Сиринә белән аралашучыларның да берсе – Гаяз.

– Нинди эш инде ул, сер булмаса?

– Хәзергә әйтә алмыйм, тик әйтми калмам, синең турыда ул.

– Әй, шаяртма әле, – диде Сиринә. Ләкин бу шаярту түгел иде.

Шымчы Гаяз дигәннән, ул үзе генә түгел, аның төркемендә тагын ике егет бар әле. Алар укый торган VIII сыйныфта тугыз гына укучы: өч егет һәм алты кыз. Әнә шул өч егет бергә детектив төркеме ясап йөргән булалар инде.

Бүген мәктәп җыелышы – линейка була, шуңа күрә барлык укучылар иртән үк килеп җиткәннәр. Гадәттәгечә, мәктәп директоры салмак тавыш белән сүзен башлады: «Хәерле иртә, укучылар, укытучылар! Менә майга да аяк бастык. Бу ай – бик мөһим ай, бигрәк тә югары сыйныфлар өчен...» Шулай итеп, директор, гадәттәгечә, тәртип, уку турында сөйләп китте.

– Укучылар! Шушы сүзләрдән соң сөендерерлек яңалык та бар: VIII сыйныф укучысы Галиева Алинә «Мин табигать яратам» дигән рәсем бәйгесендә I урын алды! Котлыйбыз!

Кайчан сүзе бетәр дә таралырбыз икән дип үз мәшәкатьләрен уйлап башлары иелгән укучыларның бер ноктага төбәлгән күзләре җанланып китте. Күптән җиңүчеләрне бүләкләгәннәре юк иде шул.

Сиринә дусты өчен бигрәк сөенде, ул дустының рәсем ясаганын белми дә иде әле.

– Бигрәк серле кеше булып чыктың әле син, Алинә. Рәсем белән мавыкканыңны миңа әйтмәгән дә идең.

– Мин шундый инде, – диде дә үзен котларга килгән иптәшләре төркеменә кушылды. Әйе, аның дуслары Сиринәдән башка да күп шул.

Шимбә көн булганга, дәресләр бик тиз үтте бүген. Мәктәп капкасыннан йөгереп чыккан балаларның якты кояшка күзләре чагылды, ләкин матурлыкка артык соклану белдермичә, бер-берләре белән куышы-куыша өйләренә таралдылар. Алинә белән Сиринәгә бер якка кайтасы. Алинә өенә кереп киткәч, Сиринә берүзе генә юлын дәвам итте. Кинәт ул: «Сиринә, көт!» – дигән тавыш ишетте. Артына борылып караса, Гаяз икән. Ул, Сиринәне куып җитеп, тын да алмыйча сөйләргә кереште:

– Сиринә, мин яңа «эшем»не сиңа әйтергә тиеш.

– Соң сөйлә.

– Беләсеңме... ни... Алинә, кыскасы, ул синең рәсемнәреңне үз исеменнән конкурска җибәргән.

Гаяз, авыр йөктән арынгандай, «уф» дип тын алып куйды. Сиринә туктап калды, берникадәр вакыт дәшми торды. Башына кинәт кенә күсәк төшкән кешедәй, җыерылып куйды.

– Юк, – диде ул, уйларыннан бүленеп, – ышанмыйм, син каян белдең соң моны?

– Минем әлегә дәлилләрем юк, тик...

Сиринә Гаязга әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде:

– Менә дәлилләрең булгач, әйтерсең, – диде дә тиз-тиз атлап китеп барды.

...Көне дә көне бүген!.. Кояш җылытуын дәвам итә. Иҗат кешеләре нәкъ шундый көннәрдән илһам ала: рәсем ясый, шигырь яза. Сиринәнең башында рәсем кайгысы түгел әле. Көн кояшлы булуга карамастан, аның күңелендә болытлар өеме. Шагыйрь халкы белми әйтми ул, иң мөһиме: күңелеңдәге кояш балкысын! Тик бу сүзләрдән соң күңел кояшының бер дә балкыйсы килми әле.

Сиринәгә ялгызы калырга, уйланырга, Гаяз әйткән сүзләрнең асылына төшенергә кирәк. Ул гадәттәгечә су буена, яраткан урынына йөгерде.

Кеше бөтенләй дә йөрми торган агачлык бар монда. Сиринәнең үз урыны ул. Ниләр генә булса да, шушы су буенда үзен иркен, рәхәт хис итә. Әнә әкрен генә инеш ага, кошлар моңланып сайрый. Җирдәге ботак-чатакларны таптый-таптый, шул урынга килеп утыргач кына Гаяз сөйләгәннәр исенә төште. Бу сүзләр бит дөрес булырга да мөмкин. Сиринә бөтенесен дә исенә төшерде: Алинәгә өч рәсем бүләк итте ул. Берсендә – җәйге болын, икенчесендә – роза чәчәкләре, өченчесендә кышкы пейзаж иде. Тизрәк Алинәнең конкурска нинди рәсемнәр җибәргәнен белергә кирәк... Дустының болай эшләве ошамады Сиринәгә. Соң, бик җибәрәсе килеп сораса, бирер иде әле, җәлләмәс иде. Шулай да үзенең рәсемнәре беренче урынны алуы сөендерә. Моңарчы ул рәсемнәрен беркая да җибәрмәде, беркемгә дә күрсәтмәде, бары тик үзе өчен генә, күңелендәге кояшының җылысын биреп кенә ясый иде. Менә бит, бер як үлчәүдә – рәсемнәр өчен сөенү, горурлык хисе, икенче якта – дустының хыянәте. Инде нишләргә? Бу Гаязын әйтерең бармы? Нигә кирәк булды икән шымчылык итү? Дөреслекне ачыклау, ялганны фаш итү өчен дисәң, хәзер инде эш узган. Акчалата бүләк тә, грамота да Алинә исеменә килгән.

Агымсуга карап, башын түбән иеп, авыр уйларга бирелеп озак утырды Сиринә. Бер мизгелгә үзен аркасына пычак кадалган кешедәй хис итте, икенче мизгелдә карурман уртасында япа-ялгыз басып калгандай тойды. Йөгерек дулкыннарның шаулавы да, кошларның дәртле сайравы да йөрәктәге сызлауны баса алмады. Үз гомерендә беренче тапкыр хыянәт ачысын кичерә ул бүген. Эндәшмик, ялгызы гына уйланырга ирек бирик без аңа... Кешеләргә ышанычы какшамасын, күңелендәге кояшы каралмасын.

Дөнья үзебезнеке

# Кычкыру һәм пышылдау



**Сиринә ТРОФИМОВА**, хәбәрче

*Бервакыт Укытучы укучыларына:*

*- Кешеләр үзара ызгышканда,ни өчен кычкыралар? - дигән сорау бирә.*

*- Тынычлыкларын югалтканга күрә,- дип җавап бирә бер укучы.*

*- Ә нигә кычкырырга соң,ул кеше синең яныңда гына бит? - ди Укытучы. Аның белән әкрен генә сөйләшеп булмыймы? Бик ачулы икәнсең,ник кычкырырга?*

*Укучылары әйтеп караган җаваплар канәгатьләндермәгәнлектән,Укытучы бу сорауларга үзе аңлатма бирә:*

*- Кешеләр бер-берсенә ризасызлык белдергәндә ызгышалар һәм бу вакыт аларның йөрәкләре дә бер-берсеннән ераклаша. Шул ераклашкан араны якынайтыр өчен һәм бер-берсен ишетер өчен,аларга кычкырырга туры килә.*

*- Ә кешеләр үзара гашыйк булганда, ничек була соң? Алар кычкырмыйлар, киресенчә,әкрен генә сөйләшәләр, чөнки аларның йөрәкләре якын һәм аралары да зур түгел. Тагын да ныграк гашыйк булганда,ничек була икән? - дип дәвам итә Укытучы. - Сөйләшмиләр, тик пышылдашалар гына һәм аларның йөрәкләре тагын да якыная төшә.*

*Соңга таба аларга пышылдашуның да кирәге калмый. Бер-берсенә карауга, алар сүзсез генә барысын да аңлыйлар. Мондый халәт яраткан кешеләр арасында гына була ала.*

*Менә шулай,дусларым,әгәр дә бәхәсләшәсез икән,йөрәкләрегезнең бер-берсеннән ераклашуына ирек куймагыз. Араларны тагын да ерагайта торган сүзләрне әйтмәгез,чөнки беркөнне сез бер-берегезгә кайту юлын мәңгегә таба алмаска мөмкинсез. Татар халкында юкка гына: «Аюны җиңгән ир - ярты ир,ачуын җиңгән ир - чын ир»,— димиләрдер...*

*(Эврил Йоханнестан хезмәтеннән)*





Студент тормышы

# Виртуаль бизнесменнар

**Динара ЗИННӘТОВА**, хәбәрче

Бүген бер генә студентны да ноутбук һәм интернет челтәреннән башка күз алдына китереп булмый. Яшьләр өчен виртуаль «пәрәвез» бүген – ул уку ярдәмлеге дә, аралашу урыны, күңел ачу мәйданы да.



Хәзер студентлар арасында интернетка бәйле тагын бер яңа тенденция – виртуаль кибетләр, интернет-бизнес булдыру зур популярлык яулап бара. Беренчел капитал таләп итмәгән бизнес ачу – студентлар өчен менә дигән мөмкинлек. Уңышка ирешү өчен башкаларны кызыксындырырлык сәләтең һәм көчле амбицияләрең булу да җитә. Хәтта тулай торакта яшәүче студентлар арасында да бүген чып-чын «виртуаль бизнесменнар» бар. Автор кулы белән эшләгән hand-made – бизәнү әйберләре, мавыктыргыч стильле блокнотлар, фотограф, оператор, тәрҗемәче хезмәтләре – боларны барысын бизнеска әйләндерү өчен, популяр социаль челтәрләрнең берәрсендә үз аккаунтың булу җитә. Биредә товарыңның фото-күргәзмәсен дә оештырырга була, реклама тарату да кыен түгел.

Казан студентлары арасында әлеге өлкәдә шактый гына нәтиҗәләргә ирешүчеләр бар һәм алар уңыш серләре белән бүлешергә әзер.

Журналистика һәм социология факультетының IV курс студенты Ләйсән Фәтхетдинова үз эшен hand-made бизәнү әйберләрен җитештерүдән башлап җибәргән. Бераз тәҗрибә җыйгач, «Вконтакте» сайтында «Шопинг онлайн» дип аталган төркем оештыра, бүген аның аша Кореядән модалы һәм креатив кием, аксессуарлар алуны гамәлгә ашыра. Үз бизнесы турында болай ди: «Әлбәттә, бераз гына булса да баер өчен, бик каты эшләргә кирәк булачак. Перспективалар сыйфаттан тора, дип уйлыйм».

Кемдер керем алуны төп максат итеп куймый һәм эшчәнлеген күңел ләззәте китергәнгә алып бара. Бу очракта уңышка ирешү мөмкинлеге күпкә арта – ихлас күңелдән башкарылган хезмәт башкалар рәтеннән һәрвакыт аерылып тора. Әлеге дә баягы «Вконтакте» сайтында «Qween of fashion» төркеме ярдәмендә Алла Матис исемле яшь кенә туташ кием-салым, косметика һәм хушбуйлар сату белән шөгыльләнә. Бүген аның аудиториясен 3 меңгә якын кеше тәшкил итә.

«Мин керем эзләмим, моның белән эш барышында рәхәтлек алу һәм кызык итеп вакыт уздыру өчен шөгыльләнәм. Бу өлкәдә мөмкинлекләр зур, чөнки күпләр өчен әйберләрне интернет аша карау һәм сайлау уңайлырак, ә виртуаль акчаларны, реаль акчалардан аермалы буларак, тоту күпкә җиңел», – дип әйтә Алла.

Үзенчәлекле товар, үтемле реклама – интернетта уңышка ирешүнең төп серләре. Безнең тормышта да шулай бит: үзеңне яңа һәм уңай яктан күрсәтә беләсең икән, уңыш озак көттерми.




DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.